**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2016 Балык Бистәсе штп. № 15пи

2016 елга Балык Бистәсе муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе тәкъдимен карап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпләрдә укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары турында» 2010 елның 6 декабрендәге 1013 номерлы карары, Татарстан республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 19 гыйнварындагы 37 пи номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры китереп КАРАР БИРӘМ:

1.2016 елга Балык Бистәсе муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын расларга;

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмаларын, әлеге карарның 1 пункты белән расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын

йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларына туры китереп, финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х. Хәбибуллин